Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий-Урай авыл җирлеге Советы

КАРАР № 2

Троицкий-Урай авылы 2023 елның 25 январе

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-Урай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Положениене раслау турында»07.12.2021 ел, №5 карары үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясындагы 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ Федераль закон нигезендә, Балык Бистәсе муниципаль районының «Троицкий-Урай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчыавыл җирлеге Советы карар кабул итә:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-урай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Положениене раслау турында " 5 номерлы 07.12.2021 карарының үз көчен югалтуын танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 , Балык Бистәсенең рәсми сайтында-Татарстан Республикасы Бистәсе муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://ribnaya - sloboda.tatarstan.ru шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий-Урай авыл җирлеге Башлыгы: Сафин Р.Х.